КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2021 ел, 15 июнь г.Казань № 454

2021 елда Татарстан Республикасы территориясендә танылган татар эшлекләләре цитаталарын баннерларда урнаштыруга бәйле чыгымнарны каплауга Татарстан Республикасы бюджетыннан юридик затларга субсидияләр бирү тәртибен раслау турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. 2021 елда Татарстан Республикасы территориясендә танылган татар эшлекләләре цитаталарын баннерларда урнаштыруга бәйле чыгымнарны каплауга Татарстан Республикасы бюджетыннан юридик затларга субсидияләр бирү тәртибен расларга.

2. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Республика «Татмедиа» матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2021 ел, 15 июнь, 454 нче
карары белән расланды

2021 елда Татарстан Республикасы территориясендә танылган татар эшлеклеләре цитаталарын баннерларда урнаштыруга бәйле чыгымнарны каплауга Татарстан Республикасы бюджетыннан юридик затларга субсидияләр бирү тәртибе

1. Әлеге Тәртип Россия Федерациясе Бюджет кодексы, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Субсидияләр бирүне җайга сала торган норматив хокукый актларга, муниципаль хокукый актларга, шул исәптән субсидияләр рәвешендә грантлар бирүне, юридик затларга, индивидуаль эшкуарларга, шулай ук физик затларга - товар, эшләр, хезмәт күрсәтүләр җитештерүчеләргә, һәм Россия Федерациясе Хөкүмәтенең кайбер актларының һәм Россия Федерациясе Хөкүмәтенең кайбер актларының үз көчләрен югалтуын тану турында гомуми таләпләр хакында» 2020 елның 18 сентябрендәге 1492 номерлы карары, Татарстан Республикасы Бюджет кодексы нигезендә эшләнгән һәм 2021 елда Татарстан Республикасы территориясендә танылган татар эшлеклеләре цитаталарын баннерларда урнаштыруга бәйле чыгымнарны каплауга Татарстан Республикасы бюджетыннан юридик затларга субсидияләр бирү механизмын (алга таба - субсидия) билгели.

Әлеге Тәртип максатлары өчен түбәндәге билгеләмәләр кулланыла:

баннер - 6 × 3 метр форматлы график сурәт, түбәндәге характеристикалар белән:

баннерлар яңа, тышкы һәм эчке җитештерү дефектларыннан башка, шартлауга югары ныклыгы, мондый продукцияне урнаштырганда кулланыла торган куркынычсызлык шартларына туры килә торган төрле һава шартларына чыдамлыгы булган, материалы тигез буялган, атмосфера йогынтысына һәм ультрашәмәхә нурланышларга чыдамлы, ялкынга бирешүчәнлеге, сыгылмалы, хезмәт срогы 6 айдан да ким булмаган сольвент буяулар булган яңа баннерлар;

баннерларда цитаталар урнаштыру - цитаталар белән баннерлар әзерләү (бастыру).

2. Субсидия бирү тиешле финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында Татарстан Республикасы законы белән каралган бюджет ассигнованиеләре күләме һәм тиешле финанс елына субсидияләр бирүгә Республика «Татмедиа» матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгына (алга таба - Агентлык) законнарда билгеләнгән тәртиптә җиткерелгән бюджет йөкләмәләре лимитлары чикләрендә гамәлгә ашырыла.

Субсидия турында белешмәләр (мәгълүмат) «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Россия Федерациясе бюджет системасының бердәм порталында (алга таба - бердәм портал) ("Бюджет» бүлегендә), шулай ук «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Агентлыкның рәсми сайтында (алга таба - Агентлыкның рәсми сайты) урнаштырыла.

3. Субсидияләр Татарстан Республикасы территориясендә эшчәнлек алып баручы һәм Татарстан Республикасы территориясендә мәгълүм татар

эшлеклеләренең Татарстан Республикасы территориясендә баннерларда цитаталарын урнаштыруга бәйле расланган чыгымнарны каплауга (алга таба - баннерларда урнашу), татар теленең милли үзенчәлеген саклап калу һәм татар халкының милли кыйммәтләрен, традицияләрен һәм гореф-гадәтләрен популярлаштыру, милли үзаңны тәрбияләү, татар халкының милли мәдәниятенә кызыксыну формалаштыру максатларында билгеләнгән тәртиптә теркәлгән, оештыру-хокукый рәвешләренә (дәүләт (муниципаль) учреждениеләреннән тыш) бәйсез рәвештә юридик затларга бирелә.

4. Субсидия алучының сайлап алуы тәкъдимнәр соратып алу юлы белән башкарыла. Сайлап алу сайлап алуда катнашучылар тарафыннан сайлап алуда катнашу өчен җибәрелгән тәкъдимнәр (гаризалар) нигезендә, сайлап алуда катнашучының сайлап алу критерийларына һәм сайлап алуда катнашуга тәкъдимнәр (гаризалар) керүнең чиратлылыгына туры килүеннән чыгып үткәрелә.

5. Субсидияләр сайлап алуны үткәрү турында игълан урнаштырылган айга кадәрге айның 1 числосына туры килә торган юридик затларга (алга таба - сайлап алуда катнашучы) түбәндәге таләпләргә бирелә:

сайлап алуда катнашучының салымнар, җыемнар, иминият кертемнәре, пенялар, штрафлар, процентлар түләү буенча салымнар һәм җыемнар турында Россия Федерациясе законнары нигезендә түләнмәгән йөкләмәләре булырга тиеш түгел;

сайлап алуда катнашучының Татарстан Республикасы бюджетына субсидияләрне, шул исәптән башка хокукый актлар нигезендә бирелгән субсидияләрне, бюджет инвестицияләрен кире кайтару буенча, шулай ук Татарстан Республикасы каршында акчалата йөкләмәләр буенча кичектерелгән (җайга салынмаган) бурычлары булырга тиеш түгел;

сайлап алуда катнашучы үзгәртеп оештыру (сайлап алуда катнашучы булган юридик затка кушу рәвешендә үзгәртеп оештырудан тыш), бетерү процессында булмау, аңа карата банкротлык процедурасы билгеләнмәгән һәм аларның эшчәнлеге Россия Федерациясе законнарында каралган тәртиптә туктатылмаган;

сайлап алуда катнашучы чит ил юридик затлары, шулай ук устав (җыелма) капиталында теркәлү урыны булып дәүләт яки территория торган, Россия Федерациясе Финанс министрлыгы тарафыннан расланган салым салуның ташламалы салым режимын бирә торган һәм (яки) мондый юридик затларга карата финанс операцияләрен (офшор зоналар) үткәргәндә мәгълүмат ачу һәм бирүне күздә тотмый торган чит ил юридик затлары, шулай ук устав (җыелма) капиталында дәүләт яки территория булып торган, Россия Федерациясе Финанс министрлыгы тарафыннан расланган счалым салуның ташламалы салым режимын;

сайлап алуда катнашучы бу Тәртипнең 3 нче пунктында күрсәтелгән максатлар өчен башка норматив хокукый актлар нигезендә Татарстан Республикасы бюджетыннан акча алучы булып тормый.

6. Сайлап алуда катнашучы түбәндәге документларны үз эченә алган тәкъдимне (гаризаны) Агентлыкка тапшыра:

Агентлык тарафыннан расланган форма буенча гариза;

гамәлгә кую документларының күчермәләре;

сайлап алуда катнашучы җитәкчесе вәкаләтләрен раслый торган документлар күчермәләре;

чыгымнарын субсидия күләмен исәпләүгә кертү планлаштырыла торган баннерлар әзерләүгә шартнамәләрнең күчермәләре;

әлеге Тәртипнең 3 пунктында күрсәтелгән максатларны гамәлгә ашыру өчен кирәкле субсидиянең иң чик күләмен әлеге Тәртипнең 18 пункты нигезендә сайлап алуда катнашучының җитәкчесе һәм баш бухгалтеры (бухгалтерлык исәбен алып бару йөкләнгән башка вазыйфаи зат) тарафыннан имзаланган, сайлап алуда катнашучының мөһере белән беркетелгән (булган очракта);

җитәкче кул куйган белешмәне сайлап алуда катнашучының мөһере белән беркетелгән (булган очракта), баннерларда (ирекле формада) урнаштыру тәҗрибәсен раслый торган белешмә;

баннерларда урнаштырылырга тиешле интеллектуаль милек объектларыннан файдалануга хокуклар барлыгын раслый торган хокук ияләре белән шартнамәләрнең күчермәләре;

сайлап алуда катнашучы җитәкчесе һәм баш хисапчысы (бухгалтерлык исәбен алып бару йөкләнгән башка вазыйфаи зат) тарафыннан имзаланган, сайлап алуда катнашучы мөһере белән беркетелгән (булган очракта), субсидияләрне күчерү өчен Россия кредит оешмасында ачылган исәп-хисап счетының реквизитларын күрсәтеп, белешмә (ирекле формада);

әлеге Тәртипнең 5 пункты белән билгеләнгән таләпләргә туры килүе турында сайлап алуда катнашучы җитәкчесе имзалаган белешмә (ирекле формада);

«Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә сайлап алуда катнашучы турында, сайлап алуда катнашучы тарафыннан бирелә торган тәкъдим (гариза), сайлап алу белән бәйле сайлап алуда катнашучы турында башка мәгълүматны бастыруга (урнаштыруга) ризалык.

Документлар сайлап алуда катнашучы тарафыннан кәгазьдә тапшырыла.

Барлык документлар да төгәл бастырылырга тиеш. Чистартулар һәм төзәтүләр рөхсәт ителми, моңа мөһер белән беркетелгән (булган очракта) һәм сайлап алуда катнашучының вәкаләтле заты имзасы белән таныкланган төзәтмәләр керми. Кәгазь чыганакта бирелгән барлык тәкъдимнәр (гаризалар) кәгазьләре тегелгән, номерланган булырга, сайлап алуда катнашучының вәкаләтле заты имзасы белән таныкланган булырга тиеш.

Тапшырыла торган белешмәләрнең дөрес булмавы өчен сайлап алуда катнашучылар Россия Федерациясе законнары нигезендә җаваплы булалар.

7. Сайлап алуда катнашучы үз теләге белән Агентлыкка түбәндәге документларны тапшырырга хокуклы:

юридик затны дәүләт теркәвенә алу турында таныклык күчермәсе йә Юридик затларның бердәм дәүләт реестры кәгазенең күчермәсе;

салым органында исәпкә кую турында таныклык күчермәсе;

салым органыннан салымнар һәм җыемнар турында Россия Федерациясе законнары нигезендә түләнергә тиешле салымнар, җыемнар, иминият кертемнәре, пенялар, штрафлар, процентлар түләү буенча үтәлмәгән бурычы булмау турында белешмә;

Юридик затларның бердәм дәүләт реестрыннан өземтә.

Сайлап алуда катнашучы әлеге пунктта күрсәтелгән документларны тапшырмаган очракта, Агентлык аларны ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек тәртибендә соратып ала.

8. Агентлык сайлап алуны уздыру турында карар кабул ителгән көннән соң өч көн эчендә бердәм порталда, шулай ук Агентлыкның рәсми сайтында сайлап алуны уздыру турында игълан урнаштыра. Тәкъдимнәрне (гаризаларны) кабул итү календарь көннәрдә, бердәм порталда, шулай ук Агентлыкның рәсми сайтында сайлап алу үткәрелү турында игълан урнаштырылган көннең иртәгесеннән исәпләнә торган көннән алып 30 көн эчендә гамәлгә ашырыла.

Сайлап алуны үткәрү турында игъланда түбәндәгеләр күрсәтелә:

сайлап алу үткәрү вакытлары (сайлап алуда катнашучылар тәкъдимнәрен (гаризаларын) тапшыру (кабул итү) башлану (тәмамланы) датасы һәм вакыты);

субсидия бирү нәтиҗәләре;

исеме, урнашу урыны, почта адресы, Агентлыкның электрон почтасы адресы;

«Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә сайлап алуны үткәрү тәэмин итеlә торган домен исемен, һәм (яки) челтәр адресын, һәм (яки) сайт битләре күрсәткечләре;

әлеге Тәртипнең 5 пункты нигезендә сайлап алуда катнашучыларга карата таләпләр һәм сайлап алуда катнашучылар тарафыннан күрсәтелгән таләпләргә туры килүен раслау өчен тапшырыла торган документлар исемлеге;

сайлап алуда катнашучылар тарафыннан бирелә торган тәкъдимнәр (гаризалар) һәм тәкъдимнәр (гаризалар) формасына һәм эчтәлегенә карата куела торган таләпләрне бирү тәртибе;

сайлап алуда катнашучыларның тәкъдимнәрен (гаризаларын) кире алу тәртибе, сайлап алуда катнашучыларның тәкъдимнәрен (гаризаларын) кире кайтару тәртибе, шул исәптән сайлап алуда катнашучыларның тәкъдимнәрен (гаризаларын) кире кайтару өчен нигезләр, сайлап алуда катнашучыларның тәкъдимнәренә (гаризаларына) үзгәрешләр кертү тәртибе;

сайлап алуда катнашучыларның тәкъдимнәрен (гаризаларын) карау кагыйдәләре;

сайлап алуда катнашучыларга сайлап алу үткәрү турында игълан нигезләмәләренә аңлатма бирү тәртибе, мондый тәкъдим итүнең башлану һәм тәмамлану вакыты;

бердәм порталда, шулай ук Агентлыкның рәсми сайтында сайлау нәтиҗәләрен урнаштыру датасы.

9. Агентлык:

тәкъдимнәр (гаризалар) кергән көнне аларны керү чираты тәртибендә журналга терки, аңа сан сугылырга, шнурланырга һәм мөһер белән беркетелгән булырга тиеш. Тәкъдимне (гаризаны) теркәгәндә номерда аның керү датасына һәм вакытына күрсәтмә булырга тиеш;

тәкъдимнәр (гаризалар) кабул итү тәмамланган көннән соң ике эш көне эчендә тапшырылган документларны сайлап алуны үткәрү турында игълан ителгән таләпләргә туры килү-килмәү турында карый, сайлап алу җиңүчеләрен билгели һәм

сайлап алуны узу турында йә сайлауда катнашучының тәкъдимен (гаризасын) кире кагу турында карар кабул итә;

сайлап алу узу турында карар кабул ителгән көнән соң 14 календарь көненнән соңга калмыйча, бердәм порталда һәм Агентлыкның рәсми сайтында түбәндәге белешмәләрне үз эченә алган сайлау нәтиҗәләре турында мәгълүмат урнаштыра:

гаризаларны карау датасы, вакыты һәм урыны;

гаризалары каралган айлап алуда катнашучылар турында мәгълүмат;

гаризалары кире кагылган сайлап алуда катнашучылар турында мәгълүмат, аларны кире кагу сәбәпләрен, шул исәптән мондый гаризалар туры килми торган сайлап алуны үткәрү турында игъланнар нигезләмәләре күрсәтеп;

сайлап алуда җиңүчеләрнең исемнәре (алга таба - субсидия алучылар) һәм аларга бирелә торган субсидия күләме.

10. Сайлап алу критерийлары түбәндәгеләр:

баннерлар әзерләү өчен шартнамәләр булу;

баннерларда урнаштырылган интеллектуаль милек объектларыннан файдалануга хокуклар булу;

баннерларда урнаштыру тәҗрибәсе булу;

әлеге Тәртипнең 3 пунктында күрсәтелгән максатларга һәм субсидия бирелә торган чыгымнар юнәлешләренә сайлап алуда катнашучы тәкъдим иткән субсидиянең иң чик күләмен исәпләп чыгаруның һәм нигезләүнең туры килүе;

сайлап алуда катнашучы билгеләнгән тәртиптә теркәлгән, Татарстан Республикасы территориясендә үз эшчәнлеген гамәлгә ашыра һәм сайлап алуны үткәрү турында игълан урнаштыру датасына кимендә биш ел кала Татарстан Республикасы бюджетына салымнар түли.

11. Сайлап алуда катнашучы сайлап алу вакыты чыкканчы тәкъдимне (гаризаны) теләсә кайсы вакытта кире алырга хокуклы.

12. Сайлап алуда катнашучының тәкъдимнәрен (гаризаларын) аны Агентлык карау стадиясендә кире кагу өчен түбәндәгеләр нигез була:

сайлап алуда катнашучының әлеге Тәртипнең 5 пунктында билгеләнгән таләпләргә туры килмәве һәм әлеге Тәртипнең 10 пунктында каралган сайлап алу критерийларына;

сайлап алуда катнашучы тарафыннан тәкъдим ителгән тәкъдимнәр (гаризалар) һәм документларның сайлап алу үткәрү турында игъланда билгеләнгән таләпләргә (гаризаларга ) туры килмәве;

сайлап алуда катнашучы биргән мәгълүматның, шул исәптән юридик затның урнашу урыны һәм адресы турындагы мәгълүматның дөрес булмавы;

сайлап алуда катнашучы тарафыннан тәкъдимнәр (гаризалар) бирү өчен билгеләнгән датадан һәм (яки) вакыттан соң тәкъдимнәр (гаризалар) бирү.

13. Субсидия бирү Агентлык белән субсидия алучы арасында төзелгән килешү нигезендә гамәлгә ашырыла. Килешү Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы билгеләгән үрнәк форма нигезендә сайлап алу нәтиҗәләре турында мәгълүмат урнаштырылган көннән алып эш көннәрендә исәпләнә торган биш көн эчендә төзелә.

Килешүдә түбәндәгеләр каралган:

субсидия күләме, аның максатчан билгеләнеше;

аны күчерү тәртибе һәм сроклары;

субсидия бирү нәтиҗәсенең мәгънәсе;

каплау өчен субсидия бирелә торган чыгымнар юнәлеше;

әлеге Тәртипнең 2 пунктында күрсәтелгән, килешүдә билгеләнгән күләмдә субсидия бирү мөмкин булмавына китерә торган, Агентлыкка моңа кадәр җиткерелгән бюджет йөкләмәләре лимитларын киметкән очракта, килешүнең яңа таләпләр буенча килешенмәгәндә килешүнең яки килешүне өзү хакында яңа шартларны килештерү турында шарт;

Агентлык һәм дәүләт финанс контроле органнары тарафыннан субсидия бирү шартлары, максатлары һәм тәртибе үтәлешенә тикшерүләр үткәрүгә субсидияләр алучының ризалыгы.

Кирәк булганда, Агентлык һәм субсидия алучы Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы тарафыннан билгеләнгән бертип формалар буенча шартнамәгә өстәмә килешү, шул исәптән шартнамәне өзү турында өстәмә килешү төзи.

14. Субсидия алучы субсидияләр алу өчен Агентлыкка субсидия бирелә торган чыгымнар барлыкка килгән кварталдан соң килүче айның 30 көненнән дә соңга калмыйча тапшырыла, әмма субсидия бирү елының 15 декабреннән дә соңга калмыйча түбәндәге документларны тапшыра:

кире кайтаруга субсидия бирелә торган фактта тотылган чыгымнарны Агентлык раслаган форма буенча исәпләп чыгару;

баннерларда урнаштыруда катнашучы штат хезмәткәрләренә штат расписаниесе;

кире кайтаруга субсидия бирелә торган фактта башкарылган чыгымнарны раслаучы документларның күчермәләре: шартнамәләр, накладнойлар, счет-фактуралар, башкарылган эшләр актлары, хезмәт хакын тотып калу һәм исәпләү.

Документларның күчермәләре субсидия алучының җитәкчесе һәм баш бухгалтеры (бухгалтерлык исәбен алып бару йөкләнгән башка вазыйфаи зат) тарафыннан таныклана һәм субсидия алучының мөһере (булган очракта) белән беркетелә.

Агентлык эш көннәрендә исәпләнә торган биш көн эчендә субсидия алучы тарафыннан бирелгән документларны терки һәм субсидия бирү турында яисә субсидия бирүдән баш тарту турында карар кабул итә.

15. Субсидия алучыга субсидия бирүдән баш тарту өчен нигез булып түбәндәгеләр тора:

«субсидия алучы тарафыннан тапшырылган документларның бу Тәртипнең 14 нче пунктында билгеләнгән таләпләргә туры килмәве яки әлеге документларның тапшырылмавы (тулы күләмдә тапшырылмавы);

субсидия алучы тарафыннан тапшырылган мәгълүматның дөрес булмавы фактын билгеләү.

Субсидия бирүдән баш тарту турында карар кабул ителгән очракта, Агентлык бу турыда эш көннәрендә исәпләнә торган ике көн эчендә субсидия алучыга хәбәр итә.

16. Агентлык субсидияне Россия Федерациясе Үзәк банкы яисә кредит оешмалары учреждениеләрендә, башкарма комитет тарафыннан субсидия бирү

турында карар кабул ителгән көннең иртәгесеннән дә соңга калмыйча, субсидия алучы тарафыннан ачылган исәп-хисап яки корреспондент счетына күчерә.

17. Кайтаруга субсидия бирелә торган баннерларда урнаштыру чыгымнары юнәлешләре:

баннерларда урнаштыруда катнашучы штатлы һәм штаттан тыш хезмәткәрләрнең хезмәте өчен түләү буенча хезмәт хакын һәм түләүләрне түләү;

авторлык һәм катнаш хокуклар буенча түләүләр, баннерларда урнаштыру максатларында дизайн эшләү һәм компьютер графикасын куллану өчен;

баннерларда урнашуга бәйле типография хезмәтләре өчен түләү;

баннерларда урнашу белән бәйле транспорт хезмәтләре өчен түләү.

18. Бирелә торган субсидиянең иң чик күләме (С) түбәндәге формула буенча билгеләнә:

$$C = З_1 + З_2 + ... + З_n + Z,$$

монда:

$З_1$, $З_2$, ..., $З_n$ - әлеге Тәртипнең 17 пунктында күрсәтелгән юнәлешләр буенча чыгымнар суммасы (штаттан тыш һәм штаттан тыш хезмәткәрләргә хезмәт өчен түләү буенча түләүгә хезмәт хакын һәм исәпләүләрне түләүдән тыш), алар Агентлык тарафыннан тиңдәш (бертөрле) товарларның, эшләрнең, хезмәт күрсәтүләрнең базар бәяләре, шул исәптән җитештерүчеләрнең бәяләре, дәүләт статистикасы органнарында булган бәяләр дәрәҗәсе, шулай ук массакүләм мәгълүмат һәм махсус әдәбият чараларында, шул исәптән «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә җитештерүчеләрнең һәм тәэмин итүчеләрнең рәсми сайтларын кертеп, билгеләнә;

Z - баннерларда урнаштыруда катнашучы штатлы һәм штаттан тыш хезмәткәрләрнең хезмәт хакы һәм хезмәт хакы түләүгә карата түләүләргә, субсидияләр исәбеннән түләнергә тиешле чыгымнар, алар хезмәткәрләрнең исәп саныннан, хисаплы вазыйфаи окладлардан, түләүләрне стимуллаштыручы вазыйфаи окладка айлык өстәмә түләүләрдән, шулай ук Россия Федерациясе законнарында каралган башка түләүләрдән чыгып, расланган штат расписаниесе нигезендә билгеләнә.

19. Субсидия бирү нәтиҗәләре баннерларда субсидия бирү елның 31 декабренә кадәр кимендә 2 700 урнаштыру булып тора.

20. Субсидия алучы  субсидия бирү елының 30 эш көненнән дә соңга калмыйча Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы билгеләгән килешүнең үрнәк формасына кушымта итеп бирелә торган форма буенча Агентлыкка субсидия бирүнең нәтиҗәсенә ирешү турында хисап тапшыра.

21. Субсидия алучы тарафыннан субсидия биргәндә билгеләнгән шартлар бозылган очракта, шул исәптән Агентлык һәм дәүләт финанс контроле органнары үткәргән тикшерүләр фактлары буенча ачыкланган, шулай ук субсидия бирү нәтиҗәсенең мәгънәсенә ирешелмәгән очракта субсидия, Агентлыкның тиешле таләбен алган көннән алып эш көннәрендә исәпләнә торган 30 көн эчендә Татарстан Республикасы бюджетына субсидия алучы тарафыннан кире кайтарылырга тиеш.

22. Субсидия алучы тарафыннан әлеге Тәртипнең 21 пунктында күрсәтелгән вакыт узганнан соң Агентлык исәпләнә торган җиде көн эчендә әлеге акчаны Татарстан Республикасы бюджетына Россия Федерациясе законнары белән билгеләнгән тәртиптә түләтү буенча чаралар күрә.

23. Агентлык һәм дәүләт финанс контроле органнары субсидия алучылар тарафыннан субсидияләр бирү шартлары, максатлары һәм тәртибенең үтәлешен мәҗбүри тикшерүне гамәлгә ашыралар.

24. Субсидия чараларын максатчан һәм нәтиҗәле куллануны тикшереп торуны Агентлык башкара.